СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

22 август, 1998 ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 96 (8253) | Бәясе билгеләнгәнчә

# ТАТАРСТАН ПРЕМЬЕР - МИНИСТРЫ - БЕЗНЕҢ РАЙОНДА

***21 августта районда Татарстан Премьер - министры Р.Н.Миннеханов булды. Аның белән бергә районга республиканың дәүләт милке белән идарә итү комитеты рәисе Д.М.Бикбов, "Таттрансгаз"ның генераль директоры Р.А.Мөслимов, Министрлар кабинетының җаваплы хезмәткәрләре һәм башка рәсми кешеләр килде, визит вакытында аны "Татнефтепром"ның генераль директоры Р.К.Зарипов, "Татмясопром" холдинг компаниясе президенты Ә. Г. Булатов һәм башка рәсми кешеләр озатып йөрде.***

***Республика хөкүмәте рәисе Зүзәй нефть промыселында булды, Төрнәс спирт заводында бара торган зур реконструкция эшләре, шулай ук районның агропромышленностендагы, бигрәк тә игенчелектәге эшләре, урып - җыюның барышы, терлекчелектә малларны бәйләүсез асрау технологиясе белән танышты. Терлекчелектә башка алдынгы технологияләрне тормышка ашыруның барышы белән кызыксынды. Премьер - министрның районга визиты программасына шулай ук Нурлат шикәр заводы, элеваторның эше белән танышу, "Нурлатнефть" НГДУсының нефть промыселларында, шәһәрдәге объектларында булу, шәһәрнең гамәлдәге, яңа төзелгән һәм төзелеп килүче социаль - мәдәни объектлары белән танышу да кертелгән иде.***

***Премьер - министрны район һәм шәһәр хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин каршы алып озатып йөрде.***

***(Р.Н.Миннехановның районга визиты турында тәфсилле язма газетабызның киләсе санында бирелачәк).***

## УРАК БАТЫРСЫЗ УЗМАС

Шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгыннан **Андрей ИВАНОВ**, Т - 4 тракторы белән бер көндә 75 гектарда ужым чәчеп, өч норма тутырды.

***

"Игенче"дән **Әсхать ИБРАҺИМОВ** К - 700 белән туңга сөрүдә икегә якын норма үти.

***

Шул ук хуҗалыктан **Ранас МИФТАХОВ** һәм **Фәнис НУРУЛЛИН** МТЗ - 80 тракторы белән ужым чәчүдә норманы 160 - 180 процентка башкаралар.

***

"Родина"дан **Николай Аркадьевич МАТВЕЕВ** "ДОН" белән 2700 центнер ашлык суктырды.

***

"Киекле"дән **Вазыйх ХАЛИТОВ** кырдан ындыр табагына 3800 центнер ашлык ташыды.

***

"Таң"нан **Вәгыйзь ГАЙФУЛЛИН** туңга сөрүдә норманы 180, Нәзир Зәйнуллин ужым чәчүдә 160 процентка үтиләр.

***

***

Мичурин исемендәге хуҗалыктан **Владимир Дмитриевич ИВАНОВ** Т- 4 тракторы белән ужым чәчүдә берьярым норма үти.

## Урак - 98

# ЯҢГЫР КУЫП ҖИТКӘНЧЕ



Яңа Иглай ул көнне үзне яңгыр белән каршы алды. Кыска вакыт эчендә авыл өстен кара болытлар каплап җирне юешләтеп тә китте. Җәй буе көттереп тә соңлап кына килгән яңгырларның урып - җыю ритмын бозуыннан борчылып, "Рассвет" КХАсы рәисе Ә.Рәхмәтуллин авыр көрсенеп куйды: "Кичә орлыкка солы суктырдык, 100 гектарга якын бодайны, арпаны теземнәргә салган идек. Тагын җыю тоткарлана инде..." Ләкин кырга чыгуга кәефләр үзгәрде: бәхеткә, явым авыл өстеннән генә узган, ә иген басулары коп - коры, алар өстендә ялтырап кояш нурлары уйный, иртә таңнан ук чыккан 6 "ДОН" комбайны, 4 ЖВН һәм 2 ЖРБ агрегатлары рәхәтләнеп эшләп яталар иде.

"Рассвет" урып - җыюда быел да район хуҗалыклары арасында алда баручыларның берсе. Моңа табигатьнең рәхимлелеге дә, электән җайга салынган тәртип тә, халыктагы тырыш, эшчән рух та һәм быелгы хәзерлек тә сәбәпче, әлбәттә. Беренчеләрдән булып алар 120 гектар җирдән борчакны суктырып алдылар, солыны суктырып бетерделәр. Аннары арпа һәм сабан бодаен аеры урып җыярга керештеләр.

Билгеле инде, уңышны мул дип булмый быел: борчак 18 - 20 центнер, солы, арпа - 15 ләр, бодайны 13 - 14ләр чамасы булыр дип көтәләр. Ә уңышның аз булуы аны тагын да кадерлерәк итә. Шуңа күрә аны югалтуларсыз җыеп алу - бүген төп бурыч. Әлегә "Рассвет" КХАсы игенчеләре бу җаваплы эшне әйбәт башкарырга тырышалар. Хуҗалыкта иң зур күрсәткеч Фәнис Төхфәтуллинныкы - ул үзенең комбайнында урак башыннан бирле 2500 центнер ашлык суктырган. Аның артыннан Нурвахит Маняпов, Василий Симакаев, Фаил Фәйзуллин, Илсур Абдуллин баралар. Минталип Гобәйдуллин, Һади Мурзаханов, Владимир Кузьмин, Харис Гайсин, Рафаэль Маняпов игеннәрне теземнәргә салып торалар.

***

"Рассвет"ның басу кырлары сөзәкле - таулы җирләргә урнашкан, нәкъ шуңа да бер кырдан башкалары уч төбендәгедәй күренеп тора. 100 гектар җирдә ямь - яшел булып тишелгән ужымны да шулай күзәттек без. Арыш һәм көзге бодай барысы 1200 гектарда чәчелергә тиеш. Бүгенгә 700 гектары чәчелгән. Калганын "чәчү срокларында төгәлләргә ниятлибез", дип ышандыралар.

***

"Рассвет"та кукуруз уруга да районда беренчеләрдән булып керештеләр. КСКда Ринат Сингатуллин, "Полесье"да Николай Тишков шактый мәйданда эш башкардылар инде. Барлыгы 725 тонна силос базга салынган. Шоферлар Илгиз Тимербулатов, Фаяз Әхмәтвәлиев, Алексей Иванов, Фәссахетдин Бикинеев, Хафиз Сатдаров хуҗалыкның барлык кырына да өлгерәләр: тапалган кукурузны да, игенне дә алар ташып тора.

Ашыгалар игенчеләр. Шулай булмый мөмкин дә түгел, тегеседәй яңгыр болыты басу - кырлар өстенә дә барып чыкмас дип кем ышандыра ала?

**_Ф.ЗЫЯТДИНОВА._**

***Рәсемнәрдә: Фаил Фәйзуллин әле яшь комбайнчы, мөстәкыйль рәвештә беренче елын гына комбайнга утырды, әмма кечкенәдән ярдәмче булып эшләүдә тупланган тәҗрибәсе аз түгел. Ярдәмчесе Рәмис Вәлиев та үзе кебек үк ут егет; агрегат эштә.***

***Н.АЗИЗОВ фотолары.***



***БҮГЕН РАЙОН УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ АВГУСТ КИҢӘШМӘСЕ АЧЫЛА. АНДА КАТНАШУЧЫЛАРГА ИҖАДИ ЭШ ТЕЛИБЕЗ!***

## "Уңыш - 98" матбугат үзәге хәбәр итә

Борчак суктыруны төгәлләгән хуҗалыклар байтак инде һәм көннәр уңай торса ул эшне тулаем тәмамларга да күп калмады.

Сабан бодаен иң күп мәйданда - 450 гектарда "Киекле" хуҗалыгы җыеп алды. Хафизов исемендәге, "Заветы Ильича", "Комбайн", Синдряков исемендәге һәм "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыкларында да ул эшне колачлы алып баралар. Дөрес, иң мөһимнәрдән булган бу культураның уңышы буенча күрсәткечләр бик чуар. Шулай да язгы бодайның тулай җыемы буенча да "Киекле" беренчелекне тота, аның артыннан Хафизов исемендәге, Мичурин исемендәге һәм "Кондырча" хуҗалыклары килә. Бодайның гектардан уңышы буенча мичуринлылар алда. "Заря" һәм "Рассвет" борчак уңышы буенча алдынгылар.

Ужым чәчүдә бу эшкә иң беренче булып тотынган хафизовлылар, "Таң", "Заветы Ильича" игенчеләре алда - аларда бу төр план яртылаш үтәлде инде. Ә менә Кузнецов исемендәге, Мичурин исемендәге, "Татарстан", шикәр заводы, РСУ ярдәмче хуҗалыкларында бу эшне кызулатасы бар әле. "Комбайн"да чәчү бөтенләй дә канәгатьләнерлек түгел.

Товар кредитын каплау исәбенә ашлык тапшыруга барлык хуҗалыклар да диярлек тотынды. 20 августка булган мәгълүматларга караганда, "Заветы Ильича" бодай белән түлисе кредитның яртысына якынын, "Төрнәс" яртысыннан күбрәген, "Кондырча" һәм нефтебаза ярдәмче хуҗалыгы өчтән берен диярлек капладылар инде. "Киекле" хуҗалыгыннан да бу максатка 264 тонна бодай керде. Иң "бодайлы" мичуринлылар да дәүләткә бурычларын кайтара башладылар. Бу көнгә товар кредиты исәбенә бодай тапшырмаган өч - "Комбайн", "Илюткино" һәм "Лесная Поляна" ярдәмче хуҗалыклары гына калган иде.

Терлек азыгы хәзерләүдә "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыгында эшләр уңай бара - сенаж салуны да тиз тотып, кукуруз силослауга да керешкәч, монда кичәге көнгә бер шартлы терлеккә әзерләнгән азык бирәмлеге 28 центнерга җитте инде. Силосны иң күп салучы - "Киекле" - анда 1600 тонна ул. Кузнецов исемендәге, нефтебаза ярдәмче хуҗалыкларында шуның яртысы кадәр, "Рассвет" һәм "Үрнәк"тә дә ишле генә.

## КРИМИНАЛЬ МӘГЪЛҮМАТ

***Нурлат шәһәр һәм район эчке эшләр бүлеге "Уңыш - 98" дигән оператив кисәтү операциясенә актив кушылды. Ул кызу урак өстендә ашлык, терлек азыгы, ягулык - майлау материалларын урлауларны кисәтү, булган очракта фактларны ачу максатыннан уздырыла. Быел уңыш чамалы гына булган хәлдә бу аеруча мөһим. Әмма анысына да кул сузарга тырышучылар булмас диеп булмый, шуңа да оператив төркем ындыр табакларын да игътибардан читтә калдырмый, кырларга да чыга, юлларда да патрульләр тота. Бу эштә участок инспекторлары да катнаша. Еш кына караклар урланган әйберләре белән үк эләгә.***

**Августның криминаль хроникасыннан.**

Биләр Озеролы Ю. туган хуҗалыгыннан 15 капчык арыш "чәлдергән". Каракның кем булуын бик тиз исәпләп чыгаралар һәм урланган ашлыгы кире кайтарыла. Октябрина поселогыннан фамилиядәш И.ләр төнге сәгать 2дә суперэлита (!) ашлыгын аракыга алыштырырга маташкан чакта тотылалар. 19нчы августта рейд барышында патруль төркеме "Татарстан" хуҗалыгында Кычытканлы авылының 4 капчык ашлык урлаган өч кешесен тота.

Бурлар терлек азыгына да кул сузалар. 17 августта Урта Камышлыда С. хуҗалыгыннан фермадан урлап кайтылган 1 центнер фураж алына. Ә Иске Әмзәнең бер кешесендә тоннага якын урланган печән табыла.

Урлау фактларының барысы буенча да тикшерү бара, берсе буенча җинаять эше кузгатыла.

Эчке эшләр бүлегенең криминаль милиция начальнигы В.Л. Гаврилов сүзләренә караганда, китергән зыяны күпме генә булуга да карамастан, урлаучыларның барысы да тиешле җәзасын алачак. Социаль-иктъисадый хәл болай да бик үк гади булмаган чакта гражданнар законга каршы бармасалар да ярар иде. Ә закон аны бозучыларны гафу итми. Быел корылыктан да күп зыян күргән иген басуы да урлаучыларны кичермәс.

***"Уңыш - 98" операциясе көзгә кадәр барачак. Бу көннәрдә районда ТР Эчке эшләр министрлыгы вәкиле дә бар.***

**_Т.АЛЕКСЕЕВА._**

# БҮГЕН - РАЙОН УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ АВГУСТ КИҢӘШМӘСЕ



### САННАР ҺӘМ ФАКТЛАР

***Узган уку елын 7 укучы - алтын, 49ы - көмеш медаль белән тәмамлады.***

***

***Балалар - үсмерләр үзәгендә кызыксынулар буенча - 10, ә мәктәпләрдә 71 түгәрәк эшләде, аларга 1755 бала йөрде.***

***

***Быел 242 педагог аттестация узды, аларның 13е - "Әйдәп баручы", 131е - I квалификация, 81е - II квалификация категориясенә лаек булды.***

## ОВС - иске яңа предмет

***Быелдан районның барлык мәктәпләрендә дә 9, 10, 11 класслар өчен яңа - ОВС - Хәрби хезмәт нигезләре фәне кертелә башлаячак.***

ОВС программасы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучы яшьләрне хәрби - патриотик тәрбияләү буенча элеккеге НВП (башлангыч хәрби хәзерлек), аннары ОБЖ (яшәеш иминлеге нигезләре) курслары программалары нигезендә милли - региональ компонентларны исәптә тотып эшләнгән.

Тәкъдим ителә торган программа өлкән класстагы егетләрне һәм кызларны әзерлекле итүне максат итә һәм укучыларга куркыныч, гадәттән тыш ситуацияләрдә сәламәтлекне саклап калу буенча белемнәр һәм күнекмәләр бирүне үз эченә ала. Ул барлыгы дүрт бүлектән тора: дәүләт оборонасы нигезләре һәм гражданнарның хәрби бурычы; гражданнар оборонасы; медицина һәм кеше сәламәтлеге культурасы белемнәре нигезләре; гамәли физик хәзерлек. Медицина белеме нигезләре буенча дәресләрне кызлар һәм егетләр белән бергә үткәрү планлаштырыла, ә әхлакый - җенси белем бирү һәм тәрбия мәсьәләләре бары тик кызлар белән генә, аерым үткәрелергә тиеш.

ОВС фәнен укыту шул ук НВП, ОБЖ курсларын алып баручы укытучыларга тапшырылачак. Безнең район мәктәпләрендә мактаулы хәрби җитәкчеләр бар: 2нче мәктәптән Н.Ә.Ханнанов, Знчедән А.И.Абрамов һәм шулай ук авыл мәктәпләреннән А.Х. Садретдинов (Югары Нурлат), Н.Н.Богаев (Мамык), И.В.Әндәров (Биккол) һәм башка укытучылар бик әйбәт эшләп килделәр.

Быел хәрби җитәкчеләргә инде онытыла башлаган эшне торгызу өчен зур эш башкарырга туры киләчәк: тирларны, каршылык полосаларын, хәрби шәһәрчекләрне аякка бастырырга кирәк, мәктәптә хәрби - патриотик тәрбияне яхшырту, бу эшкә планлылык, максатчанлык һәм системалылык белән алыну мөһим. Мәктәп музейлары, сугышчан дан бүлмәләренең эшен активлаштыру да хәрби - патриотик тәрбиянең нәтиҗәлелеген күтәрүдә зур роль уйный.

**Ә.НӘБИУЛЛИН,**
**район мәгариф бүлеге методисты.**



***"Кешене хезмәт бизи" - диләр. Ә менә мәктәптә хезмәт укытучыларының эше аларның үзләрен генә бизәп калмый, башкаларның да яшәешенә матурлык, ямь кертә. Балаларны, яңа буынны эшләргә, кул белән иҗат итәргә өйрәтү, кулларын эшкә күнектерү турында әйтәсе дә юк, хәтта. Фома урта мәктәбендә технология һәм сызым фәнен Фәнил Шаһиәхмәтов алып бара. Хуҗалыкта иң кирәкле агач әйберләр - ишекләр, өстәл - урындыкларны, тәрәзә рамнарын, бизәкләп эшләнгән киштәләрне ул үзе дә ясый, моңа укучыларны да өйрәтә. Фотохәбәрчебез Н.АЗИЗОВ аны укучысы Рөстәм Абдрахманов белән быел җәй көне Яшьләр үзәгендә үткәрелгән техник иҗат күргәзмә - конкурсында рәсемгә төшереп алган.***

## ҮЗ ЭШЕНЕҢ ОСТАСЫ

Районыбыз мәктәпләрендә еллар буе нәтиҗәле эшләп килгән, үзенең игелекле, тырыш хезмәте белән хезмәттәшләре, укучылары һәм ата - аналар ихтирамын казанган укытучылар байтак.

Шәһәрнең Знче мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Рәсимә Исхак кызы Әхмәдиева - шундыйларның берсе.

Ул үз фәнен яратуы, аны тирәнтен белүе, үзенә һәм укучыларына таләпчән булуы белән аерылып тора. Балаларның ана теле белән кызыксынуын, аларның танып - белү активлыгын көчәйтү, дәреснең нәтиҗәлелеген арттыру өчен мөгаллимә яңа педагогик технологияләрне уңышлы куллана, һәр дәресне эчтәлекле, җанлы итеп оештыра, укучыларда туган җиргә, телгә, халкыбыз тарихына ихтирам тәрбияли. Иҗади эзләнү, дәресләрдә мавыктыргыч күнекмәләр һәм биремнәр тәкъдим итү, укучылар белән үзара хезмәттәшлек булдыру укучыларда белем алуга омтылышны үстерергә, актив уйлау һәм фикер йөртү өчен шартлар тудырырга ярдәм итә.

Рәсимә Исхак кызы иҗат лабораториясен баетуга, туган як турында материаллар туплауга һәм аларны өйрәнүгә зур әһәмият бирә, дәресләрдә алардан нәтиҗәле файдалана.

Югарыда әйтелгәннәрнең нәтиҗәсе буларак, аның укучылары арасында район һәм республика олимпиадаларында катнашып, үзләрен уңай яктан күрсәтүчеләре дә бар.

Мәктәпнең татар теле укытучыларының методик берләшмәсе җитәкчесе буларак, Р.Әхмәдиева даими рәвештә секция утырышларында чыгышлар ясый, ачык дәресләр үткәрә, үзенең бай тәҗрибәсен хезмәттәшләре белән уртаклаша, үз эшенең остасы буларак, яшь мөгаллимнәргә эшлекле киңәшләрен бирә.

**Ч.ЯРУЛЛИНА,**
**мәктәпнең милли укыту - тәрбия эшләре буенча директор урынбасары.**

### Беренче тәҗрибә

## КЫШ УРТАСЫНДА ДА «ҖӘЙ» БУЛЫР

Мәктәп дигәндә иң элек ахыры булмастай тоелган, бик озак барган дәресләре, күз ачып йомганчы узып китә торган тәнәфесләре, таләпчән укытучылары белән үтә торган катлаулы тормышлы дөнья күз алдына килә. Ә менә бу җәйге көнне мин үзебезнең 4 нче мәктәбебезнең ишегалды буйлап карап йөрергә һәм анда күргәннәремне сезгә дә сөйләп бирергә булдым әле.

Мәктәп ишегалдында чәчәкләргә күмелеп утырган түтәлләр, яшел чирәм үскән газоннар, пөхтәлек һәм тәртип - барысы да укучыларның да, укытучыларның да, очраклы гына узып китүчеләрнең дә күз явын алырлык. Быел җәй тулысынча ремонтланган кышкы теплицаны күреп тә хәйран калдым мин. Төзелүенә инде ун елдан артып китсә дә, шуннан бирле аңа капиталь ремонт ясалганы булмаган, һәм быел, финанс мәсьәләсе ничек кенә авыр булуга да карамастан, бик мәшәкатьле бу эшкә алынырга батырчылык иткәннәр. Мәктәп директоры Р.Ә.Гиняеваның әйтүенә караганда, анда ремонт эшләре нигездә төгәлләнгән инде, туфрагын да китереп таратканнар, җылыту системасын тулысы белән алыштырганнар һәм бу җылы яратучы культураларны кыш буе үстерергә мөмкинлек бирәчәк.Теплицаны уртак көч белән ремонтлаганнар: НГДУ цемент һәм торба белән ярдәм иткән, мәктәптә җәйге практика узучы укучылар һәм укытучылар да бу эштә бик актив катнашканнар.

Быел теплицада суган, төрле аш тәмләткечләрдән менә дигән уңыш җыеп алганнар, 5 мең төп помидор, 3 мең төп борыч, шулай ук кәбестә уңышы үстергәннәр. Язын аларның бер өлешен мәктәп яны участогына күчереп утыртканнар, калганын - урнаштырганнар. Продукцияләрен даими алучылар да күп - сыйфат ягы да канәгатьләндерә, бәясе дә чагыштырмача арзан. Рәттән өч сезон ата торган калла һәм роза чәчәкләренә дә сорау зур.

Шундый мул уңыш үстерүчеләр кемнәр соң алар? Теплица мөдире Т.Н.Белянина һәр үсентене җан җылысы биргәндәй кадерләп карый. Мәктәптә ике елдан аз гына артыграк эшләсә дә, хезмәт сөючән һәм эшенә бик җаваплы караучы буларак коллегалары арасында зур абруй казанып өлгерде инде ул.

Теплицага шундый зур ремонт ясалу анда хезмәтне дә җиңеләйтәчәк, кышкы шартларда яшелчәләрнең үзләрен дә үстерергә мөмкинлек бирәчәк. Ә кышын монда "җәннәт почмагы" буласы - буранлы декабрьдә дә кояшлы җәйне хәтерләтеп розалар чәчәк атып утырачак.

**Д.ИДИЯТУЛЛИНА.**

***"Беренче тәҗрибә" дигән шушы рубриканы ачып, без яңа авторыбыз - югары класс укучысы Динә Идиятуллинаның язмасын тәкъдим иттек һәм башкаларны да безнең белән хезмәттәшлеккә чакырабыз. Тирә - юнегезгә күз салсагыз, анда башкаларга да сөйләп бирерлек күпме кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләр, яхшы эшләр һәм күпләрне борчыган нәрсәләр тулып ята бит. Шуңа да сездән хатлар көтеп калабыз.***

*Хатлар бүлеге.*

## ТАТАРСТАНДА САТУ САЛЫМЫ КЕРТЕЛӘ

***Татарстан Министрлар Кабинетында вице - премьер Адилә Конюшева рәислегендә министрлык һәм ведомство вәкилләре белән республикада сату салымы кертү уңаеннан киңәшмә уздырылды.***

Мәгълүм булганча, 31июльдә "Россия Федерациясенең салым системасы нигезләре турында"гы законның 20статьясына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"гы Федераль Закон игълан ителде. Бу закон нигезендә 1 сентябрьдән бөтен ил территориясендә сату салымы кертелә. Законга таянып, Федерация субъектлары салым ставкасын, түләү тәртибен һәм вакытын, аның буенча ташламаларны һәм хисап бирү формаларын, шулай ук сату салымыннан азат ителә торган товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрнең өстәмә исемлеген мөстәкыйль билгели алалар.

Татарстанда мондый салымны кертү 1998 елга республиканың бюджет системасы законы белән күздә тотылган иде инде. Ул узган елның декабрендә кабул ителде. Чөнки Федераль Салым кодексы проектында андый норма бар иде. Әмма Россия закон чыгаручылары салым законнарын яңартуны озакка сузганлыктан, бюджет турындагы республика законында сату салымы турындагы статьяның гамәлгә керүе Татарстан Президенты Указы белән туктатып торылды. Шулай итеп, закон нигезендә Татарстан яңа салымны кертүгә әзер: алкоголь продукциясе өчен 5 процентлы һәм калганнары өчен 3 процентлы ставка кертелә.

**(Ахыры 4нче биттә).**

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



*Бу көннәрдә күпмилләтле "Дуслык" район газетасы һәм Нурлат шәһәр типографиясе коллективлары зур югалту кичерде: каты авырудан соң, элекке хезмәттәшебез Роберт Зартдин улы Айзатуллин арабыздан китте.*

*Роберт Зартдинович - 25 елга якын хезмәтен безнең район газетасына биргән кеше, киң мәгълүматлы, үткен каләмле журналист иде. Редакциядә корреспонденттан бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип, мөхәррир урынбасары вазифасына кадәр үсте һәм һәр хезмәт постында тирән җаваплылык, зур тырышлык белән эшли белә иде ул. Журналист буларак иң четрекле темаларга да алынырга курыкмады, иң бәхәсле язмаларында да үз фикерендә кала белде. Шуңа аның дуслары да күп иде, дошманнары да булгандыр. Әмма ни генә булмасын, аның талантын, эшкә бирелгәнлеген, журналистлык намусын һәркем хөрмәт итте, һәркем югары бәяләде.*

*Роберт аганың таланты бер журналистлык хезмәте белән генә чикләнмәде. Ул - күп шигырьләр һәм хикәяләр авторы, аның "Ирекле тоткыннар" исемле күләмле романы "Казан утлары" журналында дөнья күреп, киң катлам укучылар тарафыннан яратып кабул ителде.*

*Аңа эшлисе дә эшлисе - эзләнәсе, язасы, иҗат итәсе иде әле. Әмма рәхимсез авыру аны әүвәл хезмәтеннән аерды, аннан якты дөньядан ук алып китте. Аңа бары 58 яшь иде.*

*Бүген без хөрмәтле хезмәттәшебезгә соңгы хушлашу сүзебезне юллыйбыз. Аның сабыр холкы, гаҗәеп эшчәнлек сәләте, хәйләсез тугрылыгы турында әледән - әле искә алабыз. Гаиләсе - Гөлбану ханым, улы һәм кызы, килене һәм оныгының авыр хәсрәтен уртаклашабыз. Тынычландырасыбыз килә - сүзләр таба алмыйбыз. Бигрәк зур югалту, бигрәк зур әрнү шул. Гомерлек әрнү.*

*Хуш, кадерле хезмәттәшебез!*

*Без сине озак еллар сагынырбыз әле, һәм һәр искә алуыбыз синә хезмәттәшләреңнең бәхиллеге, догасы булып ирешсен.*

# БАЛАГЫЗНЫҢ ТЕЛЕ АЧЫЛДЫМЫ?

Баланың сөйләшә башлавы яшь ана өчен иң шатлыклы вакыйгаларның берсе. Кайбер ата - аналар уйлаганча, баланың иртә яки соң сөйләшә башлавы һич тә аның зирәклегенә, акыл дәрәҗәсенә бәйле түгел. Монда төп рольне баланың характеры һәм әйләнә - тирә мохит уйный. Психолог Ларри Ферсон 2 мең баланың сөйләшү сәләтен тикшергән. Нәтиҗәләр мондый булган: 12 айлык балалар 50ләп сүз белә, ике яшьтәгеләрнең исә сүз хәзинәсе - 50дән алып 600гә кадәр. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, баланың сүз байлыгын арттыруда ата - ананың балага сүзләр өйрәтүе бик мөһим. Әгәр балагыз көне буе телевизор алдында утырса, аның белән аз сөйләшсәгез, әлбәттә, аның теле соңрак ачылачак.

* Бала белән сөйләшкәндә ата - аналарга менә нәрсәләргә игътибар итәргә кирәк.

* Балагыз бер сүзне дөрес әйтмәсә, мәсәлән, "шәфталу" урынына "алма" дисә, хатасын йомшак кына төзәтеп: "син алма телисең бугай" дип әйтегез. "Бу алма түгел, шәфталу бит" дип кистереп сөйләшмәгез.

* Бала белән бик ягымлы һәм ул аңларлык итеп сөйләшергә кирәк. Күп кенә ата - аналар бик тиз һәм буталчык итеп сөйләшә. Мондый вакытта бала берни аңламый кала, әлбәттә. Шуны онытмагыз: тел өйрәнгәндә башта сүзнең мәгънәсен аңларга кирәк.

*Бала белән сөйләшкәндә, аңа ярдәм итегез. Мәсәлән, ул этне күреп "Әннәм, эт" дип әйтәчәк һәм этне тасвир итәргә тырышачак. Әлбәттә, моның өчен аның сүз байлыгы җитмәячәк. Шул вакытта сез аңа булышып: "Әйе, бу - зур кара эт һәм нәрсәнедер тотарга тырыша" дисәгез, балагызның күзаллавы киңәячәк.

* Балагыз белән аның хыялларын тормышка ашырырга һәм сөйләшү сәләтен арттыруга ярдәм итә торган уеннар уйнагыз. Бала телевизор каршында озак утырмасын, чөнки телевизор караганда баланың хыяллану сәләте үсми.

Менә шуннан соң да инде сабыйның теле һаман да ачылмый икән, куркуга, пошаманга төшмәгез. Сезне ишетсә, сүзегезне аңласа, ул иртәме - соңмы барыбер сөйләшә башлаячак.

**("Заман Татарстан" нан).**

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Нурлат шәһәрендә яшәүче **этиебез Нәбиулла Хәйрулла улы Абдуллинга** 23 августта 50 яшь тула. Кадерле этиебезне юбилее белән котлап, озын гомер, бәхетнең олысын, саулык - сәламәтлек, җан тынычлыгы, әниебез белән бергә хәерле, тигез тормыш телибез.

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәшең, киявең, кызларың, улың, киленең һәм оныкларың.**

Район мәгариф бүлеге исеменнән хезмәттәшебез **Нәбиулла Хәйрулла улы Абдуллинны** юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз. Озак еллар янәшә эшләү дәверендә без аның эшлеклелек, кешелеклелек сыйфатларына, олы педагоглык талантына чын күңелдән сокландык, бүгенге юбилей көнне тагын бер кат аңа булган тирән ихтирамыбызны җиткерәсебез килә. Теләкләрнең дә иң изгеләрен юллыйбыз: сәламәт һәм тигезлектә яшәгез, һәрчак янәшәгездә тугры дуслар, ихтирамлы хезмәттәшләрегез булсын, эшегез канәгатьлек китерсен.

Бәхетле булыгыз, Нәбиулла Хәйруллович!

**Хезмәттәшләрегез.**

Хөрмәтле **Нәбиулла Хәйрулла улы Абдуллинны** юбилее белән котлыйбыз.

Бу көннәрдә сезнең юбилеегыз,
Чын күңелдән сезне котлыйбыз.
Киләчәккә шатлык, саулык белән
Тыныч тормыш теләп калабыз.

**Район мәдәният бүлеге хезмәткәрләре.**

Кадерле әниебез **Мәрбия Гата кызы Шакировага** 22 августта 50 яшь тула.

Теләкләрнең кайсын теләсәк тә,
Аз булыр күк синең хөрмәткә.
Аяз булсын синең күңел күгең -
Без калабыз шушы теләктә.

**Кызың Зөлфия, киявең, оныкларың.**

# БЕЛДЕРҮЛӘР

## САТАБЫЗ

**Азык - төлек комбинаты ягында гараж.** Адрес: Циолковский ур., 7 - 73.

***

**Якушкинода йорт, 25 сутый бакчасы бар, газы, су кергән, кыйммәт түгел.** Тел.: 5-32-92.

***

**УАЗ - 452 (салон).** Адрес: Козлов ур., 14 - 20.

***

**Гагарин ур., 4 - 1 адресы буенча телефонлы ике бүлмәле фатир.**

***

**Ашыгыч төстә әйбәт хәлдәге торак йорт. Мунчасы, йорт яны корылмалары бар.** Тел.: 2-23-93, кичке 5тән соң.

***

**Ашыгыч төстә шәһәр үзәгендә 3 бүлмәле фатир (ремонтларга кирәкми), Козлов урамында 2 бүлмәле фатир, Чишмә поселогында йорт.** Тел.: 5-14-04, кичке 8дән соң.

***

**Шикәр заводы ягында 2 бүлмәле фатир.** Адрес: Завод ур., 15 - 9, арадашчы аркылы.

***

**Бетон торба. Диаметры - 1 метр, озынлыгы - 6 метр.** Тел.: 5-15-49, 5-39-52.

***

**Цемент. Китереп бирәбез.** Тел.: 2-28-18.

***

**Азык - төлек комбинаты ягында капиталь гараж.** Адрес: Завод ур., 26 - 4, теләсә кайчан.

## ФАТИР КИРӘК

**Бер бүлмәле (шәһәр үзәгендә яки Кормыш микрорайонында булса әйбәт).** Тел.: 5-16-03.

***

**Барлык уңайлыклары белән, җиһазлы 1 яки 2 бүлмәле.** Тел.: 2-23-27, кичке 8дән соң.

*РӘХМӘТЕБЕЗ ЧИКСЕЗ*

Безнең зур кайгыбызны уртаклашкан, **улыбыз Фәнисне** соңгы юлга озатуда зур ярдәм күрсәткән элеватор коллективына һәм туганнарга, кода - кодагыйларга, дусларга, тирә - күршеләргә бик зур рәхмәтебезне белдерәбез.

**Бильдановлар гаиләсе.**

# ТАТАРСТАНДА САТУ САЛЫМЫ КЕРТЕЛӘ

**(Ахыры. Башы 2 нче биттә).**

Хәзергә сату салымы кертелми торган продукция исемлеге анык түгел әле. Федераль закон нигезендә бу исемлеккә беренче чиратта кирәкле товарлар һәм хезмәтләр кертелә. Болар - икмәк һәм икмәк - күмәч әйберләре, сөт һәм сөт продуктлары, үсемлек мае, маргарин, ярма, шикәр, бәрәңге, балалар һәм диабет белән авыручылар өчен ризыклар, балалар киеме, дару, торак - коммуналь хезмәтләр, шәһәр һәм шәһәр яны транспортында пассажирлар ташу һәм башкалар.

Татарстанда сату салымы салынмый торган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр булырмы? Адилә Конюшеваның эш төркемендә нәкъ менә шундый бәхәсләр темасы булды. Төрле фикерләр әйтелде: читтән кертелгән товарларга салымны арттыру зарурлыгы турында, мәсәлән, "дарулар", "сөт продуктлары" дигән төшенчәләрне конкретлаштыру турында... Ахыргы карар, хәзер күздә тотылганча, Татарстан Президенты указы яки Министрлар Кабинеты карары белән рәсмиләштерелер.

Бу яңалыклар бәяләрдә ничек чагылыр? Сату салымы беренче чиратта кирәкле байтак товар һәм хезмәт күрсәтүләргә кагылмаса да, Татарстанда минималь куллану кәрҗиненең кыйммәте артырга мөмкин, дип саный Адилә Конюшева. Биредә 1 августтан байтак туклану һәм балалар товарларына өстәмә кыйммәт салымы буенча ташламаларны, Пенсия фондына чигерүләр күләменең артуын исәпкә алырга кирәк. Башлангыч хисаплауларга караганда, бәядәге аерманы каплау өчен республика бюджетыннан ай саен халыкны адреслы социаль яклау программасын тормышка ашыруга 14 миллион сум акча кирәк булачак.

1 сентябрьдә бәя күрсәткечләрендә сату салымы суммасы күрсәтелгән аерым юл булырмы? Юк, дип саный вице - премьер, бәя күрсәткечтә ахыргы сумма булырга тиеш. Бик ихтимал, көндәшлек шартларында барча сәүдә предприятиеләре дә бәя күтәрүгә керешмәс, кемдер чыгымнарны эчке резервлар хисабына каплар.

Башка бер оптимистик нәрсә дә бар: яңа салым кертелү белән бер үк вакытта предприятиеләрдән кайбер салымнар һәм җыемнар юкка чыгарыла. Шулай итеп, товар җитештерүчеләргә салым йөге берникадәр җиңеләя. Сүз ваклап сату хокукы өчен җыемны, мәгариф учреждениеләре ихтыяҗларына җыемны, җирле символиканы файдалану хокукы, шәраб - аракы әйберләре, сыра белән сәүдә итү хокукы өчен лицензия җыемнарын юкка чыгару турында бара. Барлыгы ун төрле салым һәм җыем юкка чыгарылачак. Бу - продукциянең үзкыйммәтен берникадәр киметү мөмкинлеге бирер.

Түбәндәгене дә күрсәтеп узарга кирәк: сату салымыннан кергән акча тулысынча халыкның аз тәэмин ителгән төркемнәренең социаль ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә - 40 проценты республика бюджетына, 60проценты җирле бюджетка күчерелер.

**ТАТАР - ИНФОРМ.**

*Алло, редакцияме бу?*

## АЛДАДЫЛАР АХРЫСЫ...

Редакцияме әле бу? Исәнмесез?! Сез социаль темага язмалар биргәләп торасыз. Менә безнең зарны да тыңлап карагыз әле. Күптән түгел Пионер, Октябрьнең 40 еллыгы, Куйбышев һәм Красноармейская урамнарындагы биш блок йортны ("Радуга" кибете тирәсендә) НГЧ балансыннан МППга тапшырдылар. Әле апрельдә үк НГЧ түрәләре челтәр газына тоташтыру өчен дип бездән яңа акча белән 33әр сум җыеп чыкканнар иде - әлегә кадәр без җир астындагы резервуарлардагы газдан файдаланабыз, ә ул еш кына беткәләп тора. Челтәр газын тиз арада бирергә вәгъдә иттеләр, тик инде көз җитеп килсә дә, ул - бу күренми.

Бу йортларда торучыларның күбесе пенсионерлар, шуңа күрә түрәләргә барып җитәр мөмкинлегебез аз. Безнең соравыбызны газета аша аларга тапшырсагыз иде: "Акчаларыбыз кая китте икән? Әшненик сузалар, ник вәгъдәләрен үтәмиләр икән?"

***Кем шалтырата дисезме? II группа инвалид Евгений Федорович Логинов мин.***

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**


Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2353 данә. 3312